**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 14 гыйнвар

№ 8

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы; 2015 ел, 21 сентябрь, 693 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 830 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Конкурс комиссиясе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

агымдагы елның 1 мартына кадәр:

Конкурсны үткәрү вакытлары турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә;

коммерциягә карамаган оешмалар, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тәкъдимнәре нигезендә Конкурс номинацияләре исемлеген билгеләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә;

агымдагы елның 1 апреленә кадәр һәр номинация буенча экспертлар исемлеген формалаштыра һәм раслый, Конкурсны үткәрү буенча чыгымнар сметасын раслый;

агымдагы елның 1 июленә кадәр һәр номинациядә Конкурс җиңүчеләрен һәм грантлар күләмен билгели, Конкурс җиңүчеләре исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\8.docx